ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 25 октябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 5 апрелендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (алга таба – Федераль закон) гражданнарның үзләре файдалана торган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлмәгән гаражларга (алга таба – гаражлар) һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле мәсьәләләрне хәл итү өлкәсендә Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының һәм дәүләт хакимияте органнарының хокуклары**

1. Федераль закон нигезендә җирлекләрнең, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) тиешле муниципаль берәмлекләр чикләрендә урнашкан гаражлардан файдаланучы затларны (алга таба – гаражлардан файдаланучы затлар) ачыклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга һәм гражданнарга гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуда ярдәм күрсәтергә хокуклы.

2. Гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга һәм гражданнарга гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуда ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар шулай ук муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

3. Җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы әлеге статьяда күрсәтелгән объектларга карата кадастр эшләрен яисә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны тәэмин итәргә хокуклы.

3 статья. **Гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга юнәлдерелгән чаралар**

1. Гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга юнәлдерелгән чараларга түбәндәгеләр керә:

1) гаражлардан файдаланучы затлар турындагы белешмәләрне, шул исәптән архивларда һәм (яисә) җирле үзидарә органнары карамагында булган документлардагы белешмәләрне, шулай ук гаражларның, гараж һәм гараж-төзелеш кооперативларының урнашуы турындагы белешмәләрне, генераль планнарда һәм җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә булганнарын да кертеп, җыю һәм анализлау;

2) гаражлардан файдаланучы затлар турында белешмәләр алу максатларында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, шул исәптән «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм алар белән алыш-бирешне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 122-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергәнче күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны исәпкә алуны һәм теркәүне гамәлгә ашырган оешмаларга, нотариусларга гарызнамәләр җибәрү;

3) гражданнарга гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуның шартлары һәм тәртибе, шулай ук барлык кызыксынучы затлар тарафыннан гаражлардан файдаланучы затлар турында белешмәләрне җирле үзидарә органнарына җиткерү тәртибе һәм алымнары хакында мәгълүмат бирү.

2. Җирле үзидарә органнары гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашырырга хокуклы.

4 статья. **Гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру тәртибе**

1. Гражданнарга әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган мәгълүмат җиткерү тиешле мәгълүматны муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару, аны вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына, территориясендә гаражлар урнашкан торак пункт чикләрендә йә торак пункт чикләреннән читтә урнашкан башка территориядә (гаражлардан файдаланучы затларны торак пункт чикләреннән читтә ачыклау буенча эшләр башкарылган очракта) урнаштыру юлы белән, шулай ук аның максималь таралуын тәэмин итә торган башка алымнар белән гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнарына гаражлардан файдаланучы затлар турындагы белешмәләр, шул исәптән гаражларга гражданнарның хокукларын раслый торган документлар, күрсәтелгән затлар белән элемтәгә керү өчен почта адресы һәм (яисә)

электрон почта адресы турындагы белешмәләр гаражлардан файдаланучы затлар (аларның вәкаләтле вәкилләре) йә гаражлардан файдаланучы затларны ачыклау хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылырга мөмкин башка затлар тарафыннан тапшырылырга мөмкин.

3. Гаражлардан файдаланучы затлар ачыкланган очракта, җирле үзидарә органы күрсәтелгән затлар ачыкланган көннән алып 10 эш көне эчендә, гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокук алуда ярдәм күрсәтү өчен җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итеп, аларга почта аша яисә мөмкин булган башка алымнар белән мәгълүмат җибәрә.

5 статья. **Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш) №77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $6^3$ пунктчасын өстәргә:

«$6^3$) җирле үзидарә органнары тарафыннан инвалидларның яшәү урынына якын җирдә капиталь корылма булмаган гаражлар һәм инвалидларның техник һәм башка хәрәкәтләнү чараларын кую урынын урнаштыру схемаларын раслау тәртибен билгеләү;»;

2) түбәндәге эчтәлекле $6^4$ пунктчасын өстәргә:

«$6^4$) гражданнар тарафыннан капиталь корылма булмаган гаражлар кую өчен Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләреннән, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләүне билгеләү тәртибен урнаштыру;».

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан , Кремль
2021 ел, 03 ноябрь
№ 85-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ